# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге составына керүче Кара-Елга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**23.11.2022** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 12 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: " Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар һәм ялгыз өлкәннәр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Кара Елга авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2023 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- Кара Елга авылы зиратында агачлар кисү.Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 68 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 37 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 33 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 4 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Кара-Елга торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. « Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар һәм ялгыз өлкәннәр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Кара Елга авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2023 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- Кара Елга авылы зиратында агачлар кисү.» тоту мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Сәвәләй авыл җирлеге башлыгы** **И.А.Галимов**